**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“09” ноябрь 2022 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Таш-Чишмә торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чабу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү);

2) Таш-Чишмә торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

3. Г. Кутуй урамындагы “Хәлимә” чишмәсен һәм “Мәчет” коесын төзекләндерү (материал алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.